ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасында парламент контроле турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

I бүлек. **Парламент контроле нигезләре**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба – Дәүләт Советы), Дәүләт Советы Президиумы, Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре, Дәүләт Советы депутатлары, парламент тикшерүен үткәрү өчен нигез булган фактларны һәм хәлләрне тикшерү буенча парламент комиссиясе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) тарафыннан парламент контролен гамәлгә ашыруга бәйле иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Парламент контролен гамәлгә ашыруның хокукый нигезе**

Парламент контролен гамәлгә ашыруның хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән законнары, Дәүләт Советы Регламенты тәшкил итә.

3 статья. **Парламент контроле максатлары**

Парламент контроленең төп максатлары түбәндәгеләр:
1) Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен үтәүне, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын башкаруны тәэмин итү;

2) Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнгән кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау;

3) законлылык һәм хокук тәртибен ныгыту;

4) Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлегендәге төп проблемаларны ачыклау, дәүләт идарәсе системасы нәтиҗәлелеген һәм парламент контролен гамәлгә ашыру барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү максатларында аларга тиешле дәүләт органнарының һәм вазыйфаи затларның игътибар итүен арттыру;

5) коррупциягә каршы көрәш;

6) Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын куллану тәҗрибәсен өйрәнү, Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләү, шулай ук аларны башкару нәтиҗәлелеген арттыру.

4 статья. **Парламент контроле принциплары**

Парламент контроле түбәндәге принципларда гамәлгә ашырыла:

1) законлылык;

2) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәү;

3) дәүләт хакимиятенең закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләренә бүленүе;

4) парламент контроле субъектларының мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге;

5) системалылык;

6) хәбәрдарлык.

5 статья. **Парламент контроле турында мәгълүматның ачык булуы**

Дәүләт Советы, федераль законнар нигезендә файдалану мөмкинлеге чикле булган мәгълүматтан тыш, җәмгыять һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, парламент контроле турындагы мәгълүматтан һәркемнең файдалана алуын тәэмин итә.

6 статья. **Парламент контролен гамәлгә ашыру чикләре**

Парламент контролен гамәлгә ашыру суд эшчәнлеген башкаруны, җинаятьләр тикшерүне, оператив-эзләү эшчәнлеген, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә гамәлгә ашыра торган эшчәнлеген алмаштырмый. Парламент контроле субъектларының күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруга тыкшынуы рөхсәт ителми.

7 статья. **Парламент контроле субъектлары**

1. Парламент контроле субъектларына парламент контролен гамәлгә ашыру максатларында эшләүче түбәндәгеләр керә:

1) Дәүләт Советы;

2) Дәүләт Советы Президиумы;

3) Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре;

4) парламент тикшерүен үткәрү өчен нигез булган фактларны һәм хәлләрне тикшерү буенча парламент комиссиясе;

5) Дәүләт Советы депутатлары.

2. Хисап палатасы парламент контролен гамәлгә ашыруда әлеге Законда һәм «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законы) каралган очракларда, тәртиптә һәм рәвешләрдә катнаша.

8 статья. **Парламент контроле рәвешләре**

Дәүләт Советы карамагына кертелгән вәкаләтләр кысаларында парламент контролен гамәлгә ашыру эшчәнлегенә түбәндәгеләр керә:

1) Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Премьер-министрына һәм аның урынбасарларына ышанычсызлык белдерү турындагы мәсьәләне карау;

2) Дәүләт Советы, Дәүләт Советы комитетлары тарафыннан бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә башлангыч, агымдагы һәм алга таба парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын үткәрү;

3) Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Дәүләт Советы куйган мәсьәләләр буенча еллык хисапларны тыңлау;

4) Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының полиция эшчәнлеге турындагы еллык хисапларын тыңлау;

5) Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Дәүләт Советы депутатлары гарызнамәләрен, тәкъдимнәр, депутат мөрәҗәгатьләрен җибәрү;

6) Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – Министрлар Кабинеты) әгъзалары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары мәгълүматын, «хөкүмәт сәгате» кысаларында Дәүләт Советы депутатларының сорауларына күрсәтелгән вазыйфаи затларның җавапларын тыңлау, шулай ук Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышларында күрсәтелгән вазыйфаи затларның мәгълүматын тыңлау;

7) Дәүләт Советының Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән үзара эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

8) Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда һәм рәвешләрдә Хисап палатасы белән үзара эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

9) Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда һәм рәвешләрдә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән үзара эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

10) Министрлар Кабинеты әгъзаларын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затларын Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышларына чакыру;

11) парламент тыңлауларын уздыру;

12) парламент тикшерүләрен үткәрү.

9 статья. **Әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актлар чыгарганда парламент контроле**

1. Дәүләт Советы Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актларны кабул итүнең билгеләнгән срокларының Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан үтәлешен тәэмин итүне, шулай ук тиешле кимчелекләрне ачыклау максатларында тиешле хокук мөнәсәбәтләрен җайга салуның тулылыгын тикшереп тора.

2. Министрлар Кабинеты квартал тәмамланган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча Дәүләт Советына әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актларны әзерләү барышы һәм аларны кабул итүнең күз алдында тотылган сроклары турында мәгълүмат җибәрә.

II бүлек. **Парламент контроленең аерым рәвешләре**

10 статья. **Дәүләт Советы депутатлары сорауларына Министрлар Кабинеты әгъзаларының һәм башка вазыйфаи затларның җавапларын тыңлау**

1. Дәүләт Советы Министрлар Кабинеты әгъзаларын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затларын Дәүләт Советы утырышларына Дәүләт Советы депутатлары сорауларына җавапларны тыңлау өчен чакырырга хокуклы.

2. Дәүләт Советы утырышларында Дәүләт Советы депутатлары сорауларына Министрлар Кабинеты әгъзаларының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затларының җаваплары өчен вакыт («хөкүмәт сәгате») бирелергә мөмкин. Дәүләт Советы утырышына «хөкүмәт сәгате» кысаларында Министрлар Кабинеты әгъзалары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының башка вазыйфаи затлары белән бергә Хисап

палатасы эшчәнлегенең тиешле юнәлешен җитәкләүче Хисап палатасы аудиторы чакырылырга мөмкин.

3. «Хөкүмәт сәгате»н үткәрү барышында тиешле юнәлешләрдә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеге мәсьәләләре, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән расланган максатчан күрсәткечләргә ирешү мәсьәләләре буенча фикер алышу булырга мөмкин.

4. Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре үз утырышларына министрларны һәм алар вәкаләт биргән вазыйфаи затларны чакырырга хокуклы.

11 статья. **Парламент тикшерүе**

1. Парламент тикшерүе түбәндәгеләргә карата үткәрелергә тиеш :

1) Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнгән кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тупас яисә массакүләм бозу фактларына;

2) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга бәйле хәлләргә;

3) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән килгән зыяннарга бәйле хәлләргә;

4) Татарстан Республикасы бюджетының керем һәм (яисә) чыгым статьяларын күләм, структура һәм максатчан билгеләнеш буенча үз вакытында үтәмәүдә, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын тоту, Татарстан Республикасы дәүләт милкенә идарә итү һәм аның белән эш итү нәтиҗәсезлегендә чагылган финанс дисциплинасын тупас бозу фактларына.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән фактлар һәм хәлләр булганда, саны Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән берен тәшкил иткән депутатлар төркеме таләбе буенча Дәүләт Советы Президиумы, Дәүләт Советы комитеты (комитетлары) карары белән Дәүләт Советы парламент тикшерүе билгеләргә мөмкин.

3. Парламент тикшерүе Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә. Парламент тикшерүен билгеләү турындагы мәсьәлә Дәүләт Советы утырышына Дәүләт Советы карары проекты рәвешендә кертелә, анда парламент тикшерүе үткәрелергә тиешле фактлар һәм хәлләр күрсәтелә, парламент тикшерүен уздыру өчен парламент комиссиясе (алга таба – парламент комиссиясе) составы һәм парламент комиссиясе хакындагы нигезләмә билгеләнә.

4. Парламент комиссиясе Дәүләт Советы депутатлары саныннан парламент тикшерүен үткәрү вакытына комиссия рәисе, аның урынбасары, комиссия әгъзалары составында оештырыла.

5. Парламент комиссиясе утырышын комиссия рәисе, ә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары уздыра. Парламент комиссиясе утырышында комиссия әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгракы катнашса, ул тулы хокуклы була. Парламент комиссиясе карары утырышта катнашучы комиссия әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

6. Парламент комиссиясе эшен Дәүләт Советы Аппараты тәэмин итә. Парламент комиссиясенең һәр утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары парламент тикшерүен үткәрүдә кирәкле ярдәм күрсәтәләр, мәгълүмат бирү турындагы федераль законнар нигезендә парламент комиссиясе эше өчен кирәкле белешмәләрне һәм документларны тоткарлыксыз тапшыралар.

8. Парламент комиссиясе үз эшенә экспертлар җәлеп итәргә хокуклы.

9. Эш нәтиҗәләре буенча парламент комиссиясе нигезләнгән бәяләмә әзерли, анда парламент комиссиясе тикшерә торган фактлар һәм хәлләр буенча аның нәтиҗәләре булырга тиеш. Бәяләмәгә комиссия рәисе имза сала.

10. Бәяләмәне раслау турында мәсьәлә Дәүләт Советы утырышына Дәүләт Советы карары проекты рәвешендә кертелә. Бәяләмәне Дәүләт Советының сайланган депутатлары санынnan яртысыннан артыграгы хупласа, ул расланган булып санала.

11. Парламент комиссиясе бәяләмәсен раслау турындагы Дәүләт Советы карары парламент комиссиясе бәяләмәсе белән бергә дәүләт органына, җирле үзидарә органына, оешмага, тиешле вазыйфаи затларга әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән фактларны һәм хәлләрне бетерү, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү чараларын күрү өчен җибәрелә.

12 статья. **Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә Дәүләт Советы тарафыннан парламент контролен гамәлгә ашыру**

1. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендәге парламент контроленә башлангыч, агымдагы һәм алга таба гамәлгә ашырыла торган парламент контроле керә.

2. Башлангыч парламент контролен гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәгеләр башкарыла:

1) Татарстан Республикасының бюджет, салым сәясәтенең төп юнәлешләре проектлары һәм озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы проекты (бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) буенча фикер алышу;

2) Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне карау;

3) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы проекты һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты хакындагы Татарстан Республикасы законы проекты буенча фикер алышуда катнашу;

4) Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы проектын һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты хакындагы Татарстан Республикасы законы проектын карау һәм раслау.

3. Агымдагы парламент контроле кысаларында Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышларында, парламент тыңлаулары барышында, депутат гарызнамәләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре карала.

4. Алга таба гамәлгә ашырыла торган парламент контроле кысаларында Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы хисаплар карала һәм раслана. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше хакындагы еллык хисапны караганда Дәүләт Советы Татарстан Республикасы финанс министрының Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы докладын һәм Хисап палатасы Рәисенең Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше хакындагы еллык хисапка Хисап палатасы бәяләмәсе турындагы докладын тыңлый.

5. Хисап палатасы бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә парламент контролен гамәлгә ашыруда катнашуга «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәлеп ителә.

## III бүлек. **Парламент контролен планлаштыру һәм гамәлгә ашыру**

### 13 статья. **Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын планлаштыру**

1. Парламент контролен гамәлгә ашыру чаралары даими һәм бер тапкыр булырга мөмкин.

2. Парламент контролен гамәлгә ашыру чаралары Дәүләт Советы Президиумы, депутат берләшмәләре, Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре, Дәүләт Советы депутатлары тәкъдимнәре белән Дәүләт Советы чаралары планына кертелергә мөмкин.

3. Дәүләт Советы тарафыннан Хисап палатасы катнашында үткәрелә торган даими парламент контролен гамәлгә ашыру чаралары Хисап палатасының чираттагы елгы эш планына кертелә һәм «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

### 14 статья. **Парламент контролен оештыру, хокукый, методик һәм аналитик тәэмин итү**

1. Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын оештыруда һәм үткәрүдә гомуми җитәкчелекне Дәүләт Советы Рәисе һәм аның урынбасарлары гамәлгә ашыра.

2. Парламент контролен оештыру, хокукый, методик һәм аналитик тәэмин итүне Дәүләт Советы Аппараты башкара.

15 статья. **Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын үткәрү нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы карарлары**

1. Парламент контролен гамәлгә ашыру чараларын үткәрү нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасының тиешле закон проектын аны закон чыгару инициативасы тәртибендә Дәүләт Советына кертү өчен эшләүне Дәүләт Советы комитетына (комитетларына) йөкләргә, шулай ук Министрлар Кабинетына тәкъдим итәргә;

2) дәүләт органына, җирле үзидарә органына, оешмага, тиешле вазыйфаи затларга ачыкланган закон бозуларны бетерү, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү чараларын күрергә тәкъдим итәргә;

3) Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Премьер-министрына һәм аның урынбасарларына ышанычсызлык белдерү турындагы мәсьәләне карарга;

4) үз вазыйфасына билгеләп кую һәм вазыйфасыннан азат итү Дәүләт Советы карамагында булган затларны законнар белән билгеләнгән тәртиптә вазыйфадан азат итәргә;

5) Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә эшчәнлеге канәгатьләнерлек булмаган затларны вазыйфадан азат итү турындагы карарлар кабул итәргә хокуклы затларга мөрәҗәгать итәргә;

6) хокук саклау органнарына, дәүләт контроле һәм күзәтчелеге органнарына мөрәҗәгать итәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә аларның тиешле вазыйфаи затлары парламент контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы тәкъдимнәрен карарга һәм бер ай эчендә яисә Дәүләт Советы билгеләгән вакытта тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында Дәүләт Советына хәбәр итәргә тиеш. Федераль дәүләт хакимияте органнары һәм аларның вазыйфаи затлары парламент контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы тәкъдимнәрен карауны федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашыра.

16 статья. **Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $14^2$ статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2);

2) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның

29 июнендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 14 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 6 (I өлеш).

17 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 12 гыйнвары
№ 2-ТРЗ